Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

11 март 2021 ел № 28

««Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бирү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2017 елның 25 сентябрендәге 92 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. ««Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бирү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2017 елның 25 сентябрендәге 92 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- карарга 1 нче кушымтада 3 пунктның «г» пунктчасында «оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы пайлар,» сүзләреннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә,».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.Ә.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов